СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

18.07.2019 Алабуга № 376

2018 елның 13 декабрендә чыккан 311 санлы «Алабуга муниципаль районының 2019 елга, 2020 һәм 2021 елларның планлы чорына бюджеты турында»гы

Алабуга муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында Алабуга муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 83 һәм 86 маддәләренә таянып, Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР кабул итте:

1. 2018 елның 13 декабрендә чыккан 311 санлы «Алабуга муниципаль районының 2019 елга, 2020 һәм 2021 елларның планлы чорына бюджеты турында»гы Алабуга муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1 маддәдә:

*1 өлештә*

1пунктта «1 688 497,6» саннарын «1 699 816,1» саннарына алмаштырырга ;

2пунктта «1 828 385,7» саннарын «1 850 548,2» саннарына алмаштырырга;

3 пунктта «139 888,1» саннарын «150 732,1» саннарны алмаштырырга.

*3 өлештә*

«2019 елга район Бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» 1 кушымтасындагы 1 нче таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә.

2) 3 маддәдә:

«2019 елга район Бюджетының фаразланган керемнәр күләме» 2 кушымтадагы 1 нче таблицаны кабул ителә торган үзгәрешләр өлешендә бәян итәргә.

3) 6 маддәдә:

«Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджетының югары дәрәҗәдәге керемнәренең баш администраторлары исемлеге» нең 4 кушымтасы нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

4) 7 маддәдә:

«2019 елга район бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» 6 кушымтада 1 нче таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә;

«Район Бюджетының ассигновать ителгән акчаларын бүлек һәм бүлекчәләргә, максатчан маддәләргә (Алабуга муниципаль районының муниципаль программаларына һәм эшчәнлекнең программалаштырылмаган

юнәлешләренә), чыгымнар төрләре төркемнәренә, 2019 елның бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекчәләренә бүлеп бирү» 7 кушымтасында 1 номерлы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә.

«Район Бюджетының ассигновать ителгән акчаларын максатчан маддәләргә (Алабуга муниципаль районының муниципаль программаларына һәм эшчәнлекнең программалаштырылмаган юнәлешләренә), чыгымнар төрләре төркемнәренә, 2019 елның бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекчәләренә бүлеп бирү» 8 кушымтасында 1 номерлы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә.

5) 14 маддәдә:

« 2019 елга җирле әһәмияттәге сорауларны хәл итәр өчен җирлекләрнең бюджетларыннан муниципаль районның бюджетына күчерелгән бюджетара трансфертлар» 12 кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә.

**6)** 15 маддәдә:

«2019 елга өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен авыл җирлекләренә бирелгән бюджетара трансфертлар» 13 кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны икътисад үсеше, бюджет, салым, тариф сәясәте, эшмәкәрлеккә һәм туризмга ярдәм итү комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Г.Е.Емельянов